**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлегенең Көек авылында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2020 елның 13 ноябере №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Көек авылында **халык җыены карар бирә**:

1. 90% күләмендә ташлама билгеләнгән 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан кала һәр гражданга 2021 елда узарасалымны 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Курмала авылындагы Советская урамына асфальт түшәү..

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга , http:// pravo.tatarstan.ru. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин